КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 16 август г.Казань № 839

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Министрлык, сайлап алу башлану датасына кадәр 30 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасы (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 22 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 9 пункты нигезендә оешмаларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен оешмалар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 11 пункты нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 13 – 17 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү кагыйдәләрен;

коммерциягә карамаган оешмаларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләрен аңлату тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) куелырга тиешле имза кую срогын;

сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;

"Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Вәкаләтле органның "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасы, ул сайлап алу җиңүчене билгеләү көненнән соң килүче 14 календарь көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.»;

9 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү

коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Сайлап алуда катнашу өчен оешма Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

үз эченә шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә оешма турындагы, оешма бирә торган заявка турындагы мәгълүматны, тиешле сайлап алуга бәйле булган оешма турындагы башка мәгълүматны бастырып чыгаруга (урнаштыруга) ризалыгын ала торган һәм бу Тәртипнең кушымтасында бирелгән формада булган заявка;

устав, шулай ук билгеләнгән тәртиптә таныкланган барлык үзгәрешләр турында документларның күчермәләре;

бу Тәртипнең 9 пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында оешма җитәкчесе тарафыннан имза куелган белешмә кәгазен (ирекле формада);

Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә файдаланудагы Зил-131, КАМАЗ-4310 (4350, 5350 һәм аларның модификацияләре), Урал-4320 (4320-31, 43206 һәм аларның модификацияләре) маркалы уку армия автомобильләре булуын раслый торган сату-алу, аренда яисә башка документ күчермәсе;

оешма җитәкчесе тарафыннан расланган әлеге Тәртипнең 4 пункты белән билгеләнгән максатка чыгымнар сметасы, финанс-икътисадый нигезләмәне теркәп.

Бер оешма бер генә заявка бирергә мөмкин.

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Сайлап алуда катнашучы үз теләге белән Министрлыкка түбәндәге документларны тапшырырга хокуклы:

юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсен йә Юридик затларның бердәм дәүләт реестры кәгазе күчермәсен;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен;

837 («С» категорияле йөртүче) хәрби-исәп белгечлеге буенча гражданнарны әзерләүне гамәлгә ашыруга мөмкинлек бирә торган һөнәри белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия күчермәсе;

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булмау турында салым органы биргән белешмә кәгазен;

җитәкчегә, коллегиаль башкарма орган әгъзаларына, бер кеше башкарма органы функцияләрен башкаручы затларга яисә сайлап алуда катнашучының баш хисапчысына (баш хисапчы булганда) дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан өземтәләр һәм (яисә) Федераль салым хезмәте тарафыннан расланган формалар буенча соратып алынган мәгълүмат булмау турында белешмәләр;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегеннән өземтә;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә.

Сайлап алуда катнашучы тарафыннан бу пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмаган очракта, Министрлык аларны ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.»;

24 пунктта:

бишенче абзацта татар текстында «нәтиҗәләренә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «максатларны» сүзен төшереп калдырырга;

унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының, субсидия алучылар белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибе һәм шартлары (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Хисап кварталыннан соң килә торган айның 15 нче числосына кадәр, шулай ук хисап кварталыннан соң килүче елның 15 гыйнварына кадәр субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, килешү рәвешендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән рәвешләр буенча бирелә.»;

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау, Килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.»;

31 пунктта «максатларын,» сүзен төшереп калдырырга;

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карарның  2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктының кырык тугызынчы абзацыннан тыш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «837 нче хәрби-исәпкә алу белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 18 июнь, 481 нче карары белән расланган 837 нче хәрби-исәпкә алу

белгечлеге («С» категорияле йөртүче) буенча гражданнарны әзерләүгә бәйле чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 9 пунктының дүртенче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин